КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2024 ел, 12 сентябрь г.Казань № 772

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы; 2015 ел, 16 февраль, 95 нче; 2019 ел, 8 февраль, 83 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1254 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1048 нче; 2023 ел, 15 февраль, 149 нчы; 2023 ел, 29 март, 373 нче, 2023 ел, 16 июнь, 723 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турындагы нигезләмәдә:

1 пунктта:

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

тугызынчы - унберенче абзацлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

унөченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктта «2» санын «ике» сүзенә, «4» санын «дүрт» сүзенә алмаштырырга;

13 пунктта:

«б» пунктчасында «цирк,» сүзен төшереп калдырырга;

«г» һәм «д» пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты турындагы нигезләмәнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составында:

Комитет составыннан А.М.Әсәдуллинаны, Р.З.Әхиярованы, И.И.Бикеевны, Л.Д.Бикчәнтәеваны, Р.И.Вәлиевне, М.А.Волконадскийны, Г.И.Сабировны, А.Х.Шиабиевны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Галиуллин Рөстәм Госман улын | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары мәсьәләләре буенча комиссиясе әгъзасы, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Казан утлары» журналы редакциясе» филиалы баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Җәббаров Айдар Тәлгать улын | «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе режиссеры, Россия Федерациясе Президентының яшь мәдәният эшлеклеләре өчен премиясе лауреаты |
| Зәйниев Илгиз Газинур улын | «Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесенең сәнгать җитәкчесе, М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты |
| Крылов Анатолий Валентиновичны | «Россия рәссамнар берлеге» бөтенроссия иҗат оешмасының төбәк бүлекчәсенең «Татарстан рәссамнар берлеге» рәисе (килешү буенча) |
| Низамов Эльмир Җәүдәт улын | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең композиция кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, «Россия композиторлар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасы әгъзасы (килешү буенча) |
| Сәфәрова Диана Әсгать кызын | «Созвездие - Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасының арт-директоры, Халыкара спорт киносы һәм телевидениесе федерациясе әгъзасы, «Тере шәһәр» заманча сәнгатькә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган оешмасын гамәлгә куючы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Яркова Инна Игоревнаны | «Тере шәһәр» заманча сәнгатькә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин